**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 21 май № 361

г. Казань

Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу тармагында контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә предметы аларны башкару предметы белән бәйле булмаган кара-каршы йөкләмәләрне күздә тоткан бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артык вакытка товарлар китерү (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) булган дәүләт контрактларын төзү хакында карар кабул итү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлә торган Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу тармагында контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә предметы аларны башкару предметы белән бәйле булмаган кара-каршы йөкләмәләрне күздә тоткан бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артык вакытка товарлар китерү (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) булган дәүләт контрактларын төзү хакында карар кабул итү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\361.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 21 май, 361 нче карары
белән расланды

**Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу тармагында контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә предметы аларны башкару предметы белән бәйле булмаган кара-каршы йөкләмәләрне күздә тоткан бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артык вакытка товарлар китерү (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) булган дәүләт контрактларын төзү хакында карар кабул итү**
**тәртибе**

1. Әлеге Тәртип дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу тармагында контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә предметы аларны башкару предметы белән бәйле булмаган кара-каршы йөкләмәләрне күздә тоткан бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артык вакытка товарлар китерү (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) булган дәүләт контрактларын төзү хакында карар кабул итү процедурасын билгели.

2. Предметы аларны башкару предметы белән бәйле булмаган кара-каршы йөкләмәләрне күздә тоткан бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артык вакытка товарлар китерү (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) булган дәүләт контрактлары тиешле максатларга Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән бүленгән акча кысаларында төзелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы дәүләт программалары нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән түбәндәгеләр билгеләнә:

а) әгәр дәүләт контрактының предметы товарлар китерү булса:

сатып алу объекты исеме;

сатып алуны гамәлгә ашыру вакытлары;

кара-каршы йөкләмә предметы һәм аны башкару вакыты;

елларга бүлеп, китерелгән товарларга түләү чараларының чик күләме;

б) әгәр дәүләт контрактының предметы эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү булса:

сатып алу объекты исеме;

эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүнең планлаштырылган нәтиҗәләре;

сатып алуны гамәлгә ашыру вакытлары;

елларга бүлеп, башкарылган эшләргә, күрсәтелгән хезмәтләргә түләү чараларының чик күләме.

3. Татарстан Республикасы концедент булып торган концессия килешүләре бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булуы вакытларыннан

артык вакытка, концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул ителгән концессия килешүләрен төзү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә, Россия Федерациясе бюджет кодексының 79 статьясы нигезендә күрсәтелгән актлар һәм карарларда күздә тотылган вакытка кабул ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт милкенең капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында яисә Татарстан Республикасы бюджеты чаралары белән төп эш йөртүчеләре карарлары белән күздә тотылган акча кысаларында төзелә алалар.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының әлеге Тәртипнең 2 пунктында күздә тотылган предметы аларны башкару предметы белән бәйле булмаган кара-каршы йөкләмәләрне күздә токкан бюджет йөкләмәләреренең расланган лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артык вакытка товарлар китерү (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) булган дәүләт контрактларын төзү турында карары түбәндәге тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары рәвешендә кабул ителә:

а) Татарстан Республикасы дәүләт программаларын әзерләү өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын һәм аңарга аңлатманы Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына аларның Татарстан Республикасында гамәлдә булган дәүләт программаларына ярашканлыгы предметына килештерүгә җибәрәләр. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты кергән көннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын килештерә;

б) Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән килештергәннән соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты һәм аңарга аңлатма Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы килештерүгә җибәрелә;

в) Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты кергән көннән соң 10 көн эчендә, түбәндәге шартларны үтәп, күрсәтелгән проектны килештерә:

төзергә тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен дәүләт контрактының Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләре реестрына туры килүе;

агымдагы финанс елында һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен дәүләт контрактын түләүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең чик күләменең тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән тиешле чыгым йөкләмәсен башкаруга каралаган бюджет ассигнованиеләренә туры килүе;

Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен дәүләт контрактын түләүгә каралган чараларның еллык чик күләменең планлаштырылган чор кысаларында күрсәтелгән контрактка түләүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең иң күп еллык күләменнән артып китмәве;

г) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын килештерүдән баш тартылган очракта әлеге карар проекты Татарстан Республикасы дәүләт программаларын әзерләү өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына эшләп бетерү өчен җибәрелә;

д) Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән килештерелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

---

F:\KARAR\2015\361-1.docx